ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

“Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2010 елның 24 ноябрендәге 1260-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 пунктта “бүлекләрдән” сүзеннән соң “һәм Дәүләт Советы Матбугат хезмәтеннән” сүзләрен өстәргә;

2) 10 пунктта “мөстәкыйль бүлекләр мөдирләре,” сүзләреннән соң “Дәүләт Советы Матбугат хезмәте җитәкчесе,” сүзләрен өстәргә, “мөстәкыйль бүлекләр мөдирләре урынбасарлары,” сүзләреннән соң “Дәүләт Советы Матбугат хезмәте җитәкчесе урынбасары,” сүзләрен өстәргә;

3) 12 пунктта “оештыру-техник” сүзләреннән соң “, беркетмә нигезендә” сүзләрен өстәргә;

4) 14 пунктның икенче абзацында “экспертлары” сүзен “хезмәткәрләре” сүзенә алмаштырырга;

5) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16. Аппаратның Документлар белән тәэмин итү идарәсе Дәүләт Советында документлар йөрешен тәэмин итә, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы карарларының, Дәүләт Советы Рәисе, аның урынбасарлары һәм Дәүләт Советы Секретаре йөкләмәләренең, шулай ук контрольдә булырга тиешле документларның үтәлүен тикшереп тора, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы утырышларының беркетмәләрен һәм стенограммаларын алып бара, Татарстан Республикасы законнары проектларына лингвистик экспертиза ясый һәм Дәүләт Советы документларына корректор тикшерүен уздыра, Дәүләт Советы һәм аның Президиумы тарафыннан кабул ителә торган

актларны дәүләт телләренә тәрҗемә итә, Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасын, Дәүләт Советының башка басма продукциясен нәшер итә, Дәүләт Советы документларының архив фондын алып бара, Аппаратта документлар белән эшләү рәвешләрен һәм алымнарын камилләштерүне тәэмин итә, шулай ук Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламенты һәм Аппаратның Документлар белән тәэмин итү идарәсе турындагы нигезләмәдә каралган бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.";

6) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19. Дәүләт Советы Матбугат хезмәте Дәүләт Советының массакүләм мәгълүмат һәм коммуникация чаралары (алга таба – ММЧ) белән хезмәттәшлек итүен гамәлгә ашыра, Дәүләт Советы эшчәнлегенең ММЧда объектив һәм оператив яктыртылуын тәэмин итә, журналистларны аккредитацияләүне уздыра, матбугат конференцияләрен оештыра, Дәүләт Советындагы мөһим чаралар турында рәсми хәбәрләр әзерли, хәбәри материалларны Дәүләт Советы рәсми сайтына Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштыра, басма һәм электрон ММЧна көндәлек мониторинг һәм социаль медиага мониторинг ясый, социаль челтәрләрдә Дәүләт Советының рәсми аккаунтларын алып бара, республика парламентының уңай имиджын булдыру максатыннан җәмәгатьчелек белән элемтәләрне арттыруга юнәлтелгән парламент проектларын гамәлгә ашыра, Дәүләт Советы эшчәнлеге турында видео- һәм фотоконтент булдыра, "Парламент хәбәрләре"н нәшер итү эшен оештыра, шулай ук Дәүләт Советы Аппаратының Административ регламенты һәм Дәүләт Советы Матбугат хезмәте турындагы нигезләмәдә каралган бүтән функцияләрне гамәлгә ашыра.".

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Арча шәһәре,
2016 елның 21 июне
№ 1296-V ДС